**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.10.2020 № 424

**Чирмешән авылы**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «Торак бинаны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләрен һәм махсуслаштырылган торак урыннар наймы буенча типлаштырылган шартнамәләрне раслау турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы «Торак биналардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 20 сентябрендәге 475 номерлы «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 ноябрендәге 936 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы, башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмәне» расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н.Шәйдуллин

Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
23.10.2020 ел № 424

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе турында**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Чирмешән муниципаль районында муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына найм шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясе Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «Торак бинаны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләрен һәм махсуслаштырылган торак урыннар наймы буенча типлаштырылган шартнамәләрне раслау турында» карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы «Торак биналардан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» карары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 20 сентябрендәге 475 номерлы «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 15 ноябрендәге 936 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы, башка норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә муниципаль махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү тәртибен билгели.

1.3. Махсуслаштырылган торак фонды - ул муниципаль торак фондта гражданнарның аерым категорияләре яшәве өчен билгеләнгән торак урыннары җыелмасы.

1.4. Торак урынны махсуслаштырылган торак урыны буларак куллану, законнар белән билгеләнә торган тәртиптә һәм таләпләрне үтәп, мондый бинаны махсуслаштырылган торак фондына керткәннән соң гына рөхсәт ителә.

1.5. Торак бинаны махсуслаштырылган торак фондына кертү, мондый бинаны махсуслаштырылган торак биналарның билгеле бер төренә кертеп, һәм махсуслаштырылган торак фондыннан торак бинаны төшереп калдыру Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитет җитәкчесе) карары белән гамәлгә ашырыла

1.6. Махсуслаштырылган торак урыннары, законнар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә, социаль наем шартнамәләре буенча мондый торак биналарны тапшырудан тыш, читләштерелергә, алмаштырылырга, арендага, наемга бирелергә тиеш түгел.

1.7. Махсуслаштырылган торак урыннар Башкарма комитет җитәкчесе карары нигезендә махсуслаштырылган торак урыннар наймы шартнамәләре буенча бирелә.

1.8. Махсуслаштырылган торак урыннар билгеләнә:

- эшләү, хезмәт күрсәтү, укыту вакытында гражданнарның яшәве өчен;

- йортны капиталь ремонтлау яки реконструкцияләүгә бәйле рәвештә гражданнарның вакытлыча яшәве өчен;

- торак урынына түләттерү (взыскание) белдерү нәтиҗәсендә аны югалтуга бәйле рәвештә гражданнарның вакытлыча яшәве өчен;

- гадәттән тыш хәлләр аркасында яшәү өчен торак урынының яраксызлыгына бәйле рәвештә гражданнарның вакытлыча яшәве өчен;

- законнар нигезендә медицина һәм социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән социаль яклауга мохтаҗ гражданнар исәбенә кертелгән гражданнарның яшәве өчен;

- махсус социаль яклауга мохтаҗ гражданнарның яшәве өчен;

- сайланма вазыйфаларына сайлаулар яисә вазыйфага билгеләнүгә бәйле рәвештә гражданнарның вакытлыча яшәве өчен.

1.9. Махсуслаштырылган торак бинаны яллаучы шулай ук күпфатирлы йортта гомуми милек белән дә файдалана.

1.10. Махсуслаштырылган торак урыны белән кулланучы буларак яллаучы бурычлы:

а) законда, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән чикләрдә һәм билгеләнеше буенча торак урыныннан файдаланырга.

б) торак урыннарында яшәүче гражданнарның, күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне исәпкә алып, торак урыныннан файдалануны гамәлгә ашыру;

в) торак урынының сакланышын тәэмин итәргә, торак урынында аны бозуга китерә торган эшләр башкаруны яки башка гамәлләр кылуны булдырмаска;

г) торак бинаның, шулай ук күпфатирлы йортта (фатирда) гомуми кулланылыштагы биналарның тиешле торышын сакларга, торак урынында, подъездларда, лифтлар кабиналарында, баскыч мәйданчыкларында, гомуми файдаланудагы башка биналарда чисталык һәм тәртип сакларга, санитар-техник һәм башка җиһазларның сакланышын тәэмин итәргә;

д) кичекмәстән торак бинаның яисә анда булган санитар-техник һәм башка җиһазларның ачыкланган җитешсезлекләрен бетерү буенча мөмкин булган чаралар күрергә һәм кирәк булган очракта, алар турында наймга алучыга яисә тиешле идарәче компаниягә хәбәр итәргә;

е) торак бинага агымдагы ремон үткәрү;

ж) торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне вакытында кертергә. Торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү бурычы закон нигезендә махсуслаштырылган торак урыны наймы шартнамәсе төзелгәннән соң барлыкка килә;

з) алдан килештерелгән вакытта наймга бирүченең яисә аның вәкаләтле затларының, дәүләт (муниципаль) контроле һәм күзәтчелеге органнары вәкилләренең хезмәткәрләрен торак бинаның, анда булган санитар-техник һәм башка җиһазларның техник һәм санитар торышын карау өчен, шулай ук кирәкле ремонт эшләрен башкару өчен кертергә;

и) билгеләнгән тәртипне бозып, торак бинага үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны үткәрмәскә;

к) торак бинадан файдалану хокукын туктаткан очракта наймга бирүчегә акт буенча торак бинаны, анда булган санитар-техник һәм башка җиһазларны төзекләндергән хәлдә тапшырырга, яллаучының торак урынына, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларга үткәрелмәгән ремонт бәясен түләргә яки үз хисабына ремонт ясарга, шулай ук торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча бурычларны түләргә.

Яллаучы гамәлдәге законнарда каралган башка вазыйфаларны башкара.

## 2. Махсуслаштырылган торак бинаны найм шартнамәсен төзү

2.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге башкарма комитеты махсуслаштырылган торак фонды исәбен алып бара.

2.2. Махсуслаштырылган торак урыны наймы килешүе Башкарма комитет җитәкчесенең мондый бина бирү турындагы карары нигезендә төзелә.

2.3. Махсуслаштырылган торак урыны наймы килешүендә килешү предметы, махсуслаштырылган торак урыныннан файдалану буенча якларның хокуклары һәм бурычлары билгеләнә, яллаучының гаилә әгъзалары күрсәтелә.

2.4. Махсуслаштырылган торак бинаны найм килешүе язма рәвештә төзелә.

2.5. Махсуслаштырылган торак урыны наймы шартнамәсенә Башкарма комитет җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты тарафыннан, бер яктан, махсуслаштырылган торак урынын яллаучы граждан тарафыннан, икенче яктан, имза салына. Башкарма комитет җитәкчесенең яки аның вәкаләтле затының имзасы Башкарма комитет мөһере белән беркетелә.

2.6. Яллаучының гаилә әгъзалары махсуслаштырылган торак бинадан файдалану буенча аның белән тигез хокукларга һәм бурычларга ия.

## 3. Махсуслаштырылган торак урыны наймы шартнамәсен өзү һәм туктату

3.1. Махсуслаштырылган торак урыны наймы килешүе түбәндәге очракларда өзелергә мөмкин:

- яклар килешүе буенча;
- яллаучы таләбе буенча;
- Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты яисә аның вәкаләтле органы таләбе буенча.

3.2. Суд тәртибендә найм шартнамәсен өзү рөхсәт ителә:

3.2.1. торак урыны һәм (яки) коммуналь хезмәтләр өчен яллаучы тарафыннан алты айдан артык түләү кертмәү;

3.2.2. яллаучы яисә гамәлләре өчен ул җавап бирә торган башка гражданнар тарафыннан торак бинаны җимерү яисә зыян китерү;

3.2.3. күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозу, ул бер торак урынында бергә яшәүне мөмкин түгелгә әйләндерә;

3.2.4. торак урыныннан билгеләнеше буенча файдаланмау.

3.3. Яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары башка яшәү урынына чыккан очракта, махсуслаштырылган торак урыны наймы килешүе чыгу көненнән өзелгән дип санала.

3.4. Махсуслаштырылган торак урынын найм шартнамәсе мондый торак урынын югалтуга (җимерелүгә) яисә торак законнары белән каралган башка нигезләр буенча туктатыла.

3.5. Махсуслаштырылган торак урыннарны найм шартнамәсен өзү яки туктату яллаучы һәм гаилә әгъзаларында алар биләгән махсуслаштырылган торак урыннарын бушату бурычы барлыкка килүгә китерә.

3.6. Махсуслаштырылган торак бинаны бушатудан баш тарткан очракта, яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары мондый торак бинадан законнар нигезендә суд тәртибендә чыгарылырга тиеш.

## 4. Махсус торак урыны бирү турында гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итү тәртибе

4.1. Махсуслаштырылган торак урыны гражданга аның махсуслаштырылган торак урыны бирү турындагы гаризасын карау нәтиҗәләре буенча бирелә.

4.2. Махсус торак урыны бирү турында гариза (3 нче кушымта) (алга таба – гариза) Башкарма комитет җитәкчесе исеменә граждан (нотариаль расланган ышанычнамә нигезендә эш итүче аның вәкиле) тарафыннан тапшырыла яисә почта аша заказлы хат белән, тапшыру турында уведомление белән җибәрелә.

4.2.1. Гаризада түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелергә тиеш:

- мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- мөрәҗәгать итүчегә махсуслаштырылган торак урыны бирү нигезе (нигезләре) ;
- яшәү урыны буенча теркәлү турында мәгълүматлар;
- факттагы яшәү урыны адресы;
- фактта биләп торган торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документ исеме (найм, поднайм килешүе, милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык, ЕГРПтан өземтә (әгәр булса), милекченең язмача ризалыгы, яллаучының һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының, наймга бирүченең язма ризалыгы һ. б.);
- фактта биләнә торган торак урынының характеристикасы: гомуми һәм торак мәйданы, бүлмәләр саны, мөрәҗәгать итүче били торган торак урынында фактта яшәүче затлар саны;
- гаилә составы: хатыны-ире, балалары, ата-аналар, мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәүче затлар исемлеген күрсәтеп;

4.2.2. Гариза әлеге Нигезләмәнең 3нче кушымтасында күрсәтелгән форма буенча төзелә.

4.2.3. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

- гражданның һәм аның гаиләсенең һәр әгъзасының шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы;

- гражданга махсуслаштырылган торак урыны бирү хокукын раслый торган документ күчермәсе;

- барлык гаилә әгъзаларының шәхесен таныклаучы документлар, паспортлар, балалар туу турында, өйләнешү (аерылышу) турында, ата булуны билгеләү турында таныклыклар, уллыкка (кызлыкка) алу турында карарлар, гаилә әгъзасы һәм алар белән бергә яшәүче гражданнар дип тану турында суд карарлары;

- гаилә составын һәм биләп торган торак урыннарның гомуми мәйданы күләмен раслый торган документлар;

- даими яшәү урыныннан документлар: теркәлү карточкасыннан өземтә, фатир карточкасыннан өземтә, йорт кенәгәсеннән өземтә, финанс-шәхси счеттан өземтә;

- алдагы даими яшәү урыныннан документлар (йорт кенәгәсеннән өземтә, шәхси счетыннан өземтә), (гариза бирү датасына 5 елдан артмаган вакыт чорында даими яшәү урынын үзгәрткәндә);

- ИНН, СНИЛС күчермәләре;

- фактта биләп торган торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документ күчермәсе (милек хокукын дәүләт теркәве турында таныклык яки найм шартнамәсе, яки поднайм шартнамәсе, яки аренда шартнамәсе, яки күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә, яисә составына тиешле торак пункты кергән муниципаль милек реестрыннан өземтә, ул мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының тиешле торак пункттагы торак урыннарына милек яки аннан файдалану хокукы булмавын раслый), күрсәтелгән документлар вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә карамагында күрсәтелгән документлар булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарыннан һәм дәүләт органнары карамагындагы оешмалардан (алга таба - оешмалар) сорала, әгәр гражданнар күрсәтелгән документларны үз инициативасы белән тапшырмаган булса;

- мөрәҗәгать итүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта нотариаль расланган ышанычнамә һәм аның күчермәләре.

4.2.4. Башкарма комитет яисә аның вәкаләтле заты мөрәҗәгать итүчедән әлеге Нигезләмә белән билгеләнмәгән өстәмә документлар таләп итәргә хокуклы түгел.

4.2.5. Башкарма комитет яисә аның вәкаләтле заты, әгәр гаризага әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелмәгән булса, гаризаны кабул итүдән баш тарта.

4.2.6. Гариза Башкарма комитет тарафыннан махсус торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнарның гаризаларын теркәү кенәгәсендә теркәлә (5 нче кушымта). Гариза бирү көне дип мөрәҗәгать итүче тарафыннан кирәкле барлык документларны бирү көне санала.

4.2.7. Гаризаны кабул иткәндә, Башкарма комитет мөрәҗәгать итүчегә гаризаны кабул итү датасын һәм аңа кушып бирелә торган документларны, мөрәҗәгать итүченең фамилиясен, исемен, атасының исемен, гаризаны кабул иткән вәкаләтле органның вазыйфаи затын, кабул ителгән документлар исемлеген һәм аларның санын күрсәтеп, расписка-хәбәрнамә бирә (4 нче кушымта).

4.2.8. Мөрәҗәгать итүче гаризада күрсәтелгән, махсус торак урыны бирүдән баш тарту турында Башкарма комитет тарафыннан карар кабул итүнең нигезенә салынырга мөмкин булган ялган, төгәл булмаган яки тулы булмаган мәгълүматларны бирү куркынычына җаваплы.

## 5. Башкарма комитет тарафыннан махсуслаштырылган торак урыны бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итү тәртибе

5.1.1. Махсус торак урыны бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар граждан гариза биргән көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, граждан тарафыннан гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшергәннән соң кабул ителә.

5.1.2. Граждан тарафыннан гаризада күрсәтелгән белешмәләрне тикшерү дәүләт хакимиятенең тиешле органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга запрослар җибәрү юлы белән һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралган башка мәгълүмат җыю һәм тикшерү ысуллары белән гамәлгә ашырыла.

5.1.3. Башкарма комитет Иҗтимагый торак комиссиясе каравына гаризаны һәм граждан документларын кертә, аларны карау нәтиҗәләре буенча махсус фондның торак урынын бирү яисә бирүдән баш тарту турында Башкарма комитет җитәкчесенең карарын әзерли һәм билгеләнгән тәртиптә чыгара.

5.1.4. Махсус фондның торак урынын бирү яисә бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән гражданнарга мондый карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә хәбәр ителә.

5.1.5. Махсуслаштырылган торак урыны бирү турындагы карарда күрсәтелә:

- махсуслаштырылган торак урыны бирелә торган гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- аның гаилә әгъзаларының фамилияләре, исемнәре һәм әтисенең исеме;
- махсуслаштырылган торак урыны бирү шартлары (бирелә торган махсуслаштырылган торак урыны төренә карап):
- хезмәт килешүе төзү датасы, аның гамәлдә булу вакытын һәм эш бирүченең исемен күрсәтеп;
- муниципаль берәмлек вазыйфасын сайлау датасы, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты итеп сайлану датасы;
- белем бирү учреждениесенә керү датасы, уку вакыты, белем бирү учреждениесенең исеме;
- гадәттән тыш хәлнең датасы һәм характеры;
- капиталь ремонт үткәрү турында карар кабул итү датасы, капиталь ремонт үткәрү вакыты;
- салынган мөлкәткә түләттерү билгеләү (взыскание) датасы һәм нигезе, башка торак урыны сатып алу вакыты һ. б.;
- махсуслаштырылган торак урыны бирелә торган вакыт;
- бирелә торган махсуслаштырылган торак урыны төре, аның урнашу урыны, гомуми һәм торак мәйданы, бүлмәләр саны турында белешмәләр.

5.2. Махсуслаштырылган торак фондының торак урынын бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- әлеге Нигезләмәдә каралган документларны тапшырмау яки тулы булмаган күләмдә тапшыру;
- тапшырылган документлар гражданның махсуслаштырылган, маневрлы фондның торак урынын бирү хокукын расламый;
- дөрес булмаган мәгълүмат бирү.

5.3. Башкарма комитетның яисә вәкаләтле органның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокта махсуслаштырылган торак урыны бирү турында карарны кабул итмәвенә йә махсус торак урыны бирүдән баш тарту турында карарны кабул итүенә мөрәҗәгать итүче (вәкаләтле зат) тарафыннан судка шикаять бирелергә мөмкин.

## 6. Махсуслаштырылган торак урыннарын бирүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу

6.1.1. Махсуслаштырылган торак урыннары бирү турында гражданнар гаризалары һәм аларны карау буенча кабул ителгән махсуслаштырылган торак

урыннарын бирү турында карарлар нигезендә Башкарма комитет (вәкаләтле орган) махсуслаштырылган торак урыннарына мохтаҗ гражданнар исәбен алып бара (алга таба – исәпкә алу).

6.1.2. Исәпкә алу гражданнар тарафыннан махсуслаштырылган торак урыннар бирү турында гаризалар бирү датасы буенча хронологик тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6.1.3. Исәпкә алу тиешле мәгълүматларны махсуслаштырылган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу журналына кертү юлы белән гамәлгә ашырыла (5 һәм 6 нчы кушымта).

6.1.4. Исәпкә алу махсуслаштырылган торак бинаның һәр төренә карата аерым башкарыла.

6.2. Гражданнар исәптән төшерелә, әгәр:

- алар Башкарма комитет тарафыннан махсус торак урыны бирү турында карар кабул ителгән махсус торак урыны бирү турында гаризаны кире алу турында гариза бирсә;

- алар махсуслаштырылган торак урыннар бирү хокукын бирә торган нигезләрне югалтса;

- аларның үлеме.

## 7. Хезмәт торак урыннары бирү тәртибе

7.1. Муниципаль торак фондындагы хезмәт торак урыннары Чирмешән муниципаль районы территориясендә торак белән тәэмин ителмәгән гражданнарның (шулай ук гаилә әгъзаларының) хезмәт мөнәсәбәтләре характерына бәйле рәвештә яшәве өчен билгеләнгән.

7.2. Хезмәт торак урыннары гражданнарга аерым фатир рәвешендә бирелә.

7.3. Хезмәт торак урынын найм килешүе гражданнар белән исемлек буенча төзелә (1 нче кушымта).

7.4. Торак белән тәэмин ителмәгән һәм хезмәт урыны алу хокукына ия граждан үзенә хезмәт торак урыны бирү турында гариза белән Башкарма комитетка яисә аның вәкаләтле органына мөрәҗәгать итә.

7.5. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) гражданның һәм аның гаиләсенең һәр әгъзасының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;

2) хезмәткәр (гражданин) хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы эш бирүченең хезмәт торак урыны бирү турында Башкарма комитет җитәкчесе исеменә үтенеч язуы (ходатайство);

3) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт күчермәләре (барлык битләр);

4) туганлык мөнәсәбәтләренраслаучы документлар күчермәләре: туу турында таныклык, никах төзү турында таныклык, аерылышу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б.;

5) гаилә составын раслаучы документлар

6) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар күчермәләре (ордер, найм, поднайм, аренда, субаренда шартнамәсе, тулай торакка җибәрү, сату-алу, бүләк итү шартнамәсе, милек хокукы турында таныклык, закон буенча мирас хокукы турында таныклык, торак урын бирү турында карар, Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә һәм башка документлар);

7) барлык эшләүче гаилә әгъзаларыннан предприятие реквизитлары (ИНН) белән эшләү урыныннан белешмә(ләр), гражданның эш урыны, аның вазыйфасы турында җитәкченең имзасы белән имзаланган һәм оешма мөһере белән расланган белешмәләрне кертеп

8) кадрлар бүлеге җитәкчесе яки белгече тарафыннан имзаланган һәм оешма мөһере белән расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (барлык тутырылган битләр);

9) ИНН, СНИЛС күчермәләре;

Әлеге Тәртипнең 7.5 пунктындагы 6 пунктчасында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре) вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә карамагында күрсәтелгән документлар булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарыннан һәм дәүләт органнары карамагындагы оешмалардан (алга таба - оешмалар) сорала, әгәр гражданнар күрсәтелгән документларны үз инициативасы белән тапшырмаган булса. Әлеге Тәртипнең 7.5. пунктындагы 1-5, 7-9 пунктчаларында күрсәтелгән документлар вәкаләтле органга гражданнар тарафыннан тапшырыла.

7.6. Башкарма комитет яки аның вәкаләтле органы тапшырылган документларны тикшерә һәм Башкарма комитет җитәкчесенең хезмәт торак урыны бирү турындагы карары проектын әзерли.

7.7. Башкарма комитет җитәкчесе карары нигезендә хезмәт торак урынын найм килешүе төзелә.

7.8. Хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату яки сайланма вазыйфада булу, шулай ук хезмәттән азат итү хезмәт торак урынын найм шартнамәсен туктатуга нигез булып тора.

**8. Тулай торакларда торак урыннары бирү тәртибе**

8.1. Тулай тораклардагы торак урыннары муниципаль оешмаларда эшләү, хезмәт итү яки уку чорында торак урыннары белән тәэмин ителмәгән гражданнарның вакытлыча яшәве өчен билгеләнгән.

8.2. Тулай торак өчен махсус төзелгән яки шушы максатлар өчен үзгәртеп корылган торак йортлар, йә йортларның бер өлеше бирелә.

8.3. Тулай тораклардагы торак урыннары бер кешегә 6 кв.метрдан да ким булмаган торак мәйданыннан бирелә.

8.4. Тулай торакта торак урыны алу хокукына ия граждан Башкарма комитетка тулай торакта торак урыны бирү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

8.5. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) гражданның һәм аның гаиләсенең һәр әгъзасының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы;

2) хезмәткәр (гражданин) белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы эш бирүченең, граждан укый торган уку йорты җитәкчесенең Башкарма комитет җитәкчесе исеменә тулай торакта торак урыны бирү турындагы үтенечнамәсе;

3) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт күчермәләре (барлык битләр);

4) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзаларының туу турында таныклык күчермәләре;

5) туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар күчермәләре: туу турында таныклык, өйләнешү турында таныклык, аерылышу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы дип тану турында суд карары һ. б., бала туу турында белешмә - 25нче форма (әгәр дә баланың әтисе турындагы язма ана гаризасы нигезендә кертелгән булса);

6) гомуми һәм торак мәйданын күрсәтеп йорт кенәгәсеннән өземтә;

7) финанс-шәхси счеттан күчермә;

8) техник паспорт күчермәсе;

9) мөрәҗәгать итүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыныннан файдалану хокукын раслый торган документлар күчермәләре (ордер, найм, поднайм, аренда, субаренда шартнамәсе, тулай торакка җибәрү, сату-алу, бүләк итү шартнамәсе, милек хокукы турында таныклык, закон буенча мирас хокукы турында таныклык, торак урын бирү турында карар, Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә һәм башка документлар);

10) 2000 елның 1 гыйнварына кадәр тиешле муниципаль берәмлек территориясендә гражданның, шулай ук йортка кертелә торган (вселяющихся) барлык гаилә әгъзаларының, шул исәптән балигъ булмаганнарны да кертеп күчемсез милек объектларына милек хокуклары булу (булмау) турында

белешмәләр булган дәүләт техник исәпкә алу һәм (яки) техник инвентарьлаштыру буенча вәкаләтле оешманың белешмәсе;

11) барлык эшләүче гаилә әгъзаларыннан предприятие реквизитлары (ИНН) белән эшләү урыныннан белешмә(ләр), мөрәҗәгать итүченең гаиләсенә гражданның эш урыны, аның вазыйфасы турында җитәкченең имзасы белән имзаланган һәм оешма мөһере белән расланган белешмәләрне кертеп, югары уку йортларында, техникумнарда, училищеларда белем алучы студентлар өчен - ИНН күрсәтелгән уку урыннарыннан белешмә, студентлар билетларының күчермәсе, балалар бакчасыннан белешмә;

12) кадрлар бүлеге җитәкчесе яки белгече тарафыннан имзаланган һәм оешма мөһере белән расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (барлык тутырылган битләр);

13) ИНН, СНИЛС күчермәләре;

Әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы 9 пунктчасында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре) вәкаләтле орган тарафыннан законнар нигезендә карамагында күрсәтелгән документлар булган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарыннан һәм дәүләт органнары карамагындагы оешмалардан (алга таба - оешмалар) сорала, әгәр гражданнар күрсәтелгән документларны үз инициативасы белән тапшырмаган булса. Әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы 1-8, 10-13 пунктчаларында күрсәтелгән документлар вәкаләтле органга гражданнар тарафыннан тапшырыла.

8.6. Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты яки аның вәкаләтле органы документлар тикшерүен башкара һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең тулай торакта торак урыны бирү турындагы карары проектын әзерли.

8.7. Башкарма комитет җитәкчесе карары нигезендә тулай торактагы торак урынын найм килешүе төзелә.

8.8. Хезмәт мөнәсәбәтләрен, укуны туктату, шулай ук хезмәттән азат итү тулай торактагы торак урынын найм шартнамәсен туктатуга нигез булып тора.

## 9. Маневр фондының торак урыннарын бирү тәртибе

9.1. Маневр фонды торырга мөмкин күп фатирлы йортлардан, шулай ук фатирлардан һәм башка торак биналардан. Маневр фондының торак урыны гражданнарга бер кешегә 6 кв.метрдан да ким булмаган торак мәйданы исәбеннән бирелә.

Маневр фондының торак урыннары вакытлыча яшәү өчен каралган:

9.1.2. Социаль наем шартнамәләре буенча алар биләгән торак урыннары булган йортка капиталь ремонт яисә реконструкцияләнүгә бәйле рәвештә гражданнарга;

9.1.3. Банк яисә башка кредит оешмасы кредиты яисә юридик зат тарафыннан торак урыны сатып алуга бирелгән максатчан займ акчалары хисабына сатып алынган һәм кредитны яки максатчан займны кире кайтаруны тәэмин итүгә салынган торак урыннарына түләттерү(взыскание) билгеләнү нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнарга, әгәр түләттерү (взыскание) билгеләнү вакытына мондый торак урыннар алар өчен бердәнбер булып торса;

9.1.4. Гадәттән тыш хәлләр аркасында бердәнбер торак урыннары яшәү өчен яраксыз булган гражданнарга;

9.1.5. Гамәлдәге законнарда каралган очракларда башка гражданнарга.

9.2. Маневр фондының торак урынын найм килешүе түбәндәге вакытка төзелә:

- йортка капиталь ремонт яки реконструкция эшләре тәмамланганчы;

- түләттерү(взыскание) билгеләнгән торак урыннарын сатканнан соң, түләттерү (взыскание) билгеләнү нәтиҗәсендә торак урыннарын югалткан гражданнар белән исәп-хисаплар тәмамланганчы;

- гадәттән тыш хәлләр аркасында яшәү өчен яраксызга әйләнгән бердәнбер торак урыны булган гражданнар белән исәп-хисап ясау тәмамланганчы яисә аларга дәүләт һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары бирелгәнче;

- закон белән билгеләнгән.

9.3. Маневрлы фондның торак урынын найм шартнамәсе төзелгән чор бетү әлеге килешүне туктату өчен нигез булып тора.

## 10. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы йортларында торак урыннары бирү

10.1. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү системасы йортларындагы торак урыннары законнар нигезендә медицина һәм социаль-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү белән махсус социаль яклауга мохтаҗ гражданнар исәбенә кертелгән гражданнарга яшәү өчен билгеләнә.

10.2. Халыкка социаль хезмәт күрсәтү һәм мондый торак урыннардан файдалану системасы йортларында торак урыннары бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

## 11. Мәҗбүри күченүчеләр һәм качак дип танылган затларның вакытлыча урнашуы өчен фондларның торак урыннарын бирү

11.1. Мәҗбүри күченүчеләр һәм качак дип танылган затлар өчен вакытлыча урнашуы өчен фондларның торак урыннары федераль законда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри күченүчеләр һәм качаклар дип танылган гражданнарның вакытлыча яшәве өчен билгеләнгән.

11.2. Мәҗбүри күченүчеләр һәм качак дип танылган затларга вакытлыча урнашу өчен фондларның торак урыннары бирү тәртибе Россия Федерациясе законнары белән билгеләнә.

## 12. Гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау өчен торак урыннары бирү

12.1. Гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау өчен торак урыннары законнар нигезендә махсус социаль яклауга мохтаҗ гражданнар исәбенә кертелгән гражданнар өчен билгеләнгән.

12.2. Махсус социаль яклауга мохтаҗ гражданнар категорияләре Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.

12.3. Гражданнарның аерым категорияләрен социаль яклау өчен торак урыннарын түләүсез файдалану шартнамәләре буенча бирү Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган торак фондының
махсуслаштырылган торак урыннарына
наем шартнамәләре буенча торак урыннары
бирү тәртибе турында Нигезләмәгә

**Муниципаль махсуслаштырылган торак фондында хезмәт торак урыннары бирелә торган гражданнар категорияләре исемлеге**

Хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм зур ихтыяҗ кичерә торган белгечлекләр (вазыйфалар) хезмәткәрләре дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләргә, шулай ук муниципаль учреждениеләргә караган түбәндәге өлкәләрдә:

- сәламәтлекне саклау;
- мәгариф;
- мәдәният;
- яшьләр һәм спорт;
- чакырылган Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнары Җитәкчеләренә һәм белгечләренә;
- прокуратура хезмәткәрләренә;
- Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә урнашкан башка бюджет учреждениеләре хезмәткәрләре.

2нче кушымта

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган торак фондының
махсуслаштырылган торак урыннарына
наем шартнамәләре буенча торак урыннары
бирү тәртибе турында Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенә
______________________________________
от ____________________________________
______________________________________
(фамилия, исем, атасының исеме)
туу датасы _________________________
паспорт ________________________________
_______________________________________
(серия һәм номер, паспорт биргән орган исеме
бирү датасы, бүлекчә коды)
яшәү урыны буенча киләсе адреста
теркәлгән: __________________
_______________________________________
Почта адресы: ________________________
________________________________________
_______________________________________
Телефон _______________________________
Эш урыны __________________________
________________________________________
________________________________________
Вазыйфа _______________________________
_________________________________________

## Махсуслаштырылган торак фондының хезмәт торак урынын бирү турында ГАРИЗА

**Миңа махсус торак фондының хезмәт торак урынын бирүегезне сорыйм түбәндәгеләр нигезендә:**

дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, дәүләт яисә муниципаль унитар предприятиесе, дәүләт яки муниципаль учреждение белән, хезмәт үтү сәбәпле, Россия Федерациясе дәүләт вазыйфасына яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт вазыйфасына билгеләнүгә йә дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына сайланма вазыйфаларга сайлануга бәйле рәвештә, хезмәт мөнәсәбәтләре характеры белән.

хезмәт мөнәсәбәтләренең характеры, хезмәт узу, Татарстан Республикасы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләнү, дәүләт хакимияте органнарына сайланулы вазыйфаларга сайлану, Татарстан Республикасы чикләрендә башка җирдә урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт органына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен билгеләү белән–**кирәклесеннең астына сызарга**

**Минем гаилә әгъзалары:**
**ир** (хатын) ______________________________________________________________________________,
**(фамилия, исем, әтисенең исеме,туу елы)**

**паспорт**______________________________________________________________________________
**(серия һәм номер, паспорт биргән орган исеме, бирү датасы, бүлекчә коды)**

______________________________________________________________________________,

яшәү урыны буенча **киләсе адреста теркәлгән** ________________________________________;
**Балалар:**
**1.** ______________________________________________________________________________,
**(фамилия, исем, әтисенең исеме,туу елы)**

**паспорт** (туу турында таныклык) ________________________________________________________
**(серия һәм номер, паспорт (туу турында таныклык) биргән орган исеме, бирү датасы)**

______________________________________________________________________________,

яшәү урыны буенча киләсе адреста **теркәлгән**: ________________________________________
______________________________________________________________________________;

**2.** ______________________________________________________________________________,
**(фамилия, исем, әтисенең исеме,туу елы)**

**паспорт** (туу турында таныклык) ________________________________________________________
**(серия һәм номер, паспорт (туу турында таныклык) биргән орган исеме, бирү датасы)**

______________________________________________________________________________,

яшәү урыны буенча киләсе адреста **теркәлгән**: ________________________________________
______________________________________________________________________________;

**Ата-аналар:**
**1.** ______________________________________________________________________________,
**(фамилия, исем, әтисенең исеме,туу елы)**

**паспорт**
______________________________________________________________________________
**(серия һәм номер, паспорт (туу турында таныклык) биргән орган исеме, бирү датасы)**

______________________________________________________________________________,

яшәү урыны буенча киләсе адреста теркәлгән: ________________________________________

___________________________________________________________________________;

**2.__________________________________________________________________________,**

**(фамилия, исем, әтисенең исеме,туу елы)**

**паспорт**______________________________________________________________________

**(серия һәм номер, паспорт биргән орган исеме, бирү датасы),**

___________________________________________________________________________,

яшәү урыны буенча киләсе адреста теркәлгән: ___________________________________

___________________________________________________________________________.

**Моннан тыш,** минем иждивениемдә балигъ булмаган, эшкә сәләтсез (яки чикләнгән эшкә яраклы) граждан (гражданнар):_________________________________________,

**(фамилия, исем, әтисенең исеме,туу елы)**

**паспорт (**туу турында таныклык) ___________________________________________

**(серия һәм номер, паспорт (туу турында таныклык) биргән орган исеме, бирү датасы)**

___________________________________________________________________________,

яшәү урыны буенча киләсе адреста теркәлгән: ___________________________________

___________________________________________________________________________.

**Минем гаилә әгъзалары белән берлектә хезмәт торак урыны бирүегезне сорыйм:**

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________.

**(туганлык дәрәҗәсе, Ф.И.О.)**

**Имза** ___________________________/_________________________/

**(фамилия, исем, әтисенең исеме)**

**Дата «___» ______________ 20_____ ел**

**Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:**

1. тиешле дәүләт органы, җирле үзидарә органы, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиесе, Татарстан Республикасы дәүләт яки муниципаль учреждениесе җитәкчесенең үтенечнамәсе;

2. гражданның (үзенең һәм гаиләнең балигъ булмаган әгъзаларының) һәм аның гаиләсенең һәр балигъ булган әгъзасының шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгы;

3. мөрәҗәгать итүченең һәм гаилә әгъзаларының шәхесен раслаучы документлар күчермәләре;

4. мөрәҗәгать итүченең туганлык мөнәсәбәтләрен раслаучы документлар күчермәләре (никах теркәү турында таныклык, аерылышу турында таныклык, балалар туу турында таныклык)

5. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә хезмәт мөнәсәбәтләрен раслый торган документ (кадрлар органы раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе, дәүләт яки муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр хезмәт шартнамәсенең күчермәсе, хезмәт контрактының күчермәсе);

6. дәүләт вазыйфасына билгеләп кую турында документ;

7. дәүләт хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына сайлаулар турында документ

8. даими яшәү урыныннан документлар (йорт кенәгәсеннән өземтә, финанс-шәхси счеттан өземтә);

9. элеккеге яшәү урыныннан документлар (йорт кенәгәсеннән өземтә, финанс-шәхси счеттан өземтә), ( гариза бирү датасына 5 елдан артмаган вакыт чорына даими тору урынын үзгәрткәндә);

10. ИНН, СНИЛС күчермәләре.

3 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган торак фондының
махсуслаштырылган торак урыннарына
наем шартнамәләре буенча торак урыннары
бирү тәртибе турында Нигезләмәгә

**Муниципаль торак фондының**
**махсуслаштырылган торак урынын**
**бирү турында гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган**
**документларны алу турында**
**расписка**

Әлеге белән раслана, мөрәҗәгать итүче ______________________________
тапшырды, ____________________________________________________________

*(җирле үзидарә органының вазыйфаи заты күрсәтелә)*

кабул итте «_____» _______________ ________ ел вхд.№ __________ түбәндәге документларны:

| *№* | *Документның исеме* | *битләр саны* | *документлар күчермәләре* |
|---|---|---|---|
| 1. | Гариза | | |
| 2. | | | |
| 3. | | | |
| 4. | | | |
| 5. | | | |
| 6. | | | |
| 7. | | | |
| 8. | | | |
| 9. | | | |
| 10. | | | |

______________________ (_____________________)
*М.У.*

4нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган торак фондының
махсуслаштырылган торак урыннарына
наем шартнамәләре буенча торак урыннары
бирү тәртибе турында Нигезләмәгә

**Муниципаль торак фондының махсуслаштырылган торак урынын бирү турында гражданнарның гаризаларын теркәү кенәгәсе**

| №п/п | Вхд.№ | Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.О. | Гаризаның керү датасы | Гаризаны кабул иткән зат имзасы | Җаваплы башкаручы | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

5нче кушымта
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
муниципаль махсуслаштырылган торак фондының
махсуслаштырылган торак урыннарына
наем шартнамәләре буенча торак урыннары
бирү тәртибе турында Нигезләмәгә

## Махсуслаштырылган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу журналы

**1 кисәк.** Хезмәт торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнар

| № п/п | Гариза бирү датасы | Хезмәт торак урыны алу нигезе | Хезмәт торак урыны бирү турында карар кабул итү датасы | Хезмәт торак урынының фактта бирелү датасы | Хезмәт торак урыны бирү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

**2 кисәк.** Тулай торакларда торак урыннары бирүгә мохтаҗ гражданнар

| № п/п | Гариза бирү датасы | Тулай торакта торак урыны алу нигезе | Тулай торакта торак урыны бирү турында карар кабул итү датасы | Тулай торакта торак урынын фактта бирү датасы | Тулай торакта торак урыны бирү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |

**3 кисәк.** Маневр фондының торак урыннарын бирүгә мохтаҗ гражданнар

| № п/п | Гариза бирү датасы | Маневрен фондының торак урынын алу нигезе | Маневр фондының торак урынын бирү турында карар кабул итү датасы | Маневр фондының торак урынын фактта бирү датасы | Маневр фондының торак урынын бирү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |